САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 289 30.01.2015

№ _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 98 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасын төзү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы турында Положениегә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

– 3.1 пункт. Нигезләмәләрне түбәндәге эчтәлекле 3.1.29 пунктчасы белән тулыландырырга: « 3.1.28. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турындагы законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә тикшереп тора».

2. Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисенә Федераль салым хезмәтенең ТР буенча 10нчы районара инспекциясендә Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов